**СОВЕТ МАСАДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
423753, деревня Масады,
ул. Нефтяников ,дом 18 ,
Тел. 3-44-49

**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МЭСЭДЕ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
423753, Мэсэде авылы,
Нефтяниклар ур.,18 нче йорт.
Тел. 3-44-49

№ 9 21.11.2020 ел

РЕШЕНИЕ КАРАР

«Актаныш муниципаль районы Мәсәде авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану турында»

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, 28.07.2004 ел, № 45-ЗРТ «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, «Мәсәде авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге Уставының 25 статьясына, Актаныш муниципаль районы Мәсәде авыл җирлеге Советы

Карары:

1.Мәсәде авыл җирлеге территориясендә 2021 нче елда, 1 нче төркем инвалидларыннан, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләүләр кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә.:

**Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

- Мәсәде Бурсык авылларында юлларны ремонтлау һәм карап тоту (ПГС салу, грейдлау,кардан чистарту).

**Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**

- янгын сүндерү өчен су цистернасы алу;

-авыл җирлегенең ташландык участокларын чистарту, куаклар һәм агачлар кисү, объектларны сүтү һәм участокларны тоту;

**Җирләү урыннарын карап тоту һәм ритуаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру:**

-Бурсык авылы зираты коймасын тоту.

**Халыкка торак-коммуналь, көнкүреш һәм башка хезмәт күрсәтү өлкәсендә эш оештыру:**

- урам яктырткычларын һәм электр челтәрләрен карау.

**Җирлек халкына массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру һәм халык күпләп ял итә торган урыннарны төзекләндерү:**

- рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын оештыру һәм уздыру

2. Актаныш муниципаль районы Мәсәде авыл җирлеге гражданнарының авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында җыелу нәтиҗәләрен игълан итәргә.

3. Актаныш муниципаль районы Мәсәде авыл җирлеге гражданнарының җыены нәтиҗәсен Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында "Авыл җирлеге"бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

Мәсәде авыл җирлеге

Советы башлыгы: Минһаҗетдинова Ф. Р.